ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.05.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1545**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 декабрендәге 2630 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләр – педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь белгечләр – педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү билгеләү турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 ноябрендәге 979 номерлы карары нигезендә. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләр – педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 03 декабрендәге 2630 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 маендагы 1127 номерлы, 2023 елның 07 июнендәге 1696 номерлы, 2025 елның 09 июлендәге 1816 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне искә алып) расланган. Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләр – педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 нче пунктта:
«2 510 сум» сүзен «10 000 сум» сүзенә алмаштырырга;

1.2. 15 нче пунктта:
«2 510 сум» сүзен «10 000 сум» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге начальнигына «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru. ) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин